РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» июнь 2021ел г. Альметьевск № 887

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 23 октябрендәге 1535 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 23 октябрендәге 1535 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

2 бүлек таблицасында 2 графада 2.5. пунктындагы алтынчы абзацның 1) пунктчасын төшереп калдырырга;

2 бүлек таблицасында 2 графада 2.5. пунктындагы алтынчы абзацның 3) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гражданның гаилә составы турындагы документларның күчермәләре: чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аларның нотариаль танылканган рус теленә тәрҗемәсе, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һәм башкалар;»;

2 бүлек таблицасында 2 графада 2.5. пунктындагы беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле 5) пунктча өстәргә:

«5) гражданлык хәле актлары язмаларының Бердәм дәүләт реестрында туу, никахны теркәү һәм өзү турында дәүләт теркәве белешмәләре гражданлык

Зак. № 305-2000

хәле актлары язмаларының Бердәм дәүләт реестрында туу, никахны теркәү һәм өзү турында актларына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында белешмәләр.»;

2 бүлек таблицасында 2 графада 2.15. пунктындагы унөченче абзацны төшереп калдырырга;

административ регламентка 2 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова А.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ